СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**«15» май, 2019 ел** **№ 78**

Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары
һәм Яңа Кырлай авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренә
хезмәт өчен түләү күләме һәм шартлары турында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасын Кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставы нигезендә Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Расларга:

Даими нигездә муниципаль вазыйфалар башкаручы затларга хезмәт өчен түләү турында Нигезләмәне (1 Кушымта).

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын алыштыручы затларга хезмәт өчен түләү турында Нигезләмәне (2 Кушымта).

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралган хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү турында Нигезләмәне (3 Кушымта).

Баш хисапчыга хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмәне (4 Кушымта).

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүдә эшләүче эшчеләргә хезмәт өчен түләү разрядлары диапазонын (5 Кушымта).

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре тариф коэффициентлары һәм тариф ставкаларын (окладлары) (6 Кушымта).
Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге хезмәткәрләренә компенсация түләүләре күләмен (7 Кушымта).

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2018 елның «25» апрелендә, №54 “Арча муниципаль районы жирле үзидарә органнары һәм Яңа Кырлай авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү күләме һәм шартлары турында” карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында Яңа Кырлай авыл җирлеге бүлегендә бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар аны рәсми рәвештә бастырып чыгарган (халыкка җиткергән) көннән үз көченә керә һәм 2019 елның 01 апреленнән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сафаров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012702

Яңа Кырлай авыл
җирлеге Советының
2019 ел, «15» май, 78 нче
карарына
1 Кушымта

**Даими нигездә муниципаль вазыйфалар башкаручы затларга хезмәт өчен түләү турында Нигезләмә**

Әлеге Нигезләмә ТР Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Башлыгына хезмәт өчен түләү тәртибен билгели.
«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә ТР Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге хезмәт өчен түләүнең унберенче төркеменә – халык саны 1 мең ярымнан 5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләргә керә.
Даими нигездә муниципаль вазыйфаны алыштыручы затка хезмәте өчен түләү акчалата түләү формасында башкарыла.

| Вазыйфа исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Башлыгы | 16750 |

ТР Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Башлыгына айлык акчалата түләүдән тыш билгеләнә:
- айлык акчалата бүләкләү;
- тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләү;
- эш нәтиҗәләре буенча премия;
- еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү;
- матди ярдәм.

Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата бүләкләү елга унбер айлык акчалата түләү күләменнән артмаган күләмдә билгеләнә.

ТР Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгына тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә билгеләнә:

| Муниципаль вазыйфаларда стаж булганда | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан артык | 20 |

ТР Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгына тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләүгә чыгымнар күләме елга өч айлык акчалата түләү күләменнән арта алмый.

Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр башкарган өчен премия түбәндәге шартларны исәпкә алып түләнә:

1) премияләр вазыйфаи күрсәтмәләр һәм хезмәт килешүләре белән каралган вазыйфаларны вакытында һәм сыйфатлы итеп башкарган; җитәкчелекнең биремнәрен, әмерләрен һәм боерыкларын вакытында һәм сыйфатлы итеп үтәгән өчен премия түләү турында карар кабул ителгән көнгә җирле үзидарә органы белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган, даими нигездә муниципаль вазыйфаларны алыштыручы затларга түләнә;

2) башка эшкә күчү, уку йортларына керү, әзерлек (квалификация), белем күтәрү курсларында уку, хезмәткәрләр яки штатны кыскарту буенча эштән китү, пенсиягә китү, йөклелек вакыты һәм бала табу буенча ялга китү, өч яшькә кадәр бала ялына китү һәм башка нигезле сәбәпләр белән бәйле рәвештә премия исәпләү өчен алынган вакыт аралыгында тулысынча эшләмәгән, даими нигездә муниципаль вазыйфаны алыштыра торган затларга премия әлеге исәп вакыт аралыгында фактта эшләнгән вакыт өчен түләнә. Даими нигездә муниципаль вазифаны алыштыручы затларга авыру буенча эштә булмаган вакыт өчен премия түләү һәр аерым очракта эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан карала;

3) премия исәпләү өчен алынган вакыт аралыгында җирле үзидарә органына эшкә кабул ителгән затларга премия аларның хезмәт өлешен исәпкә алып һәм фактта эшләнгән вакыт өчен түләнергә мөмкин;

4) календар ел дәвамында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны алыштыручы затларга премия хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә исәпләнә;

5) премия исәпләү өчен вакыт аралыгы итеп айга, кварталга, яртыеллыкка, елга яки биремнәрне башкару өчен билгеләнгән башка вакытка тигез булган вакыт аралыгы алына;

6) премия суммалары максималь күләм белән чикләнмәгән;

7) даими нигездә муниципаль вазыйфаларны алыштыручы аерым затларга, аларның гомуми эш нәтиҗәсенә керткән шәхси өлешен исәпкә

алып, премия күләме арттырылырга мөмкин;

8) җитештерү ялгышы җибәргән һәм хезмәт дисциплинасын бозган даими нигездә муниципаль вазыйфаларны башкаручы затлар тулысынча яки өлешчә премиядән мәхрүм ителә.

Тулысынча яки өлешчә премиядән мәхрүм итү җитештерү ялгышы һәм хезмәт дисциплинасын бозуга юл куелган премия түләү өчен алынган вакыт аралыгы өчен башкарыла.

Катлаулы һәм киеренке хезмәт өчен айлык өстәмә түләү, биремнәрнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге дәрәҗәсеннән чыгып, акчалата түләүнең 15 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.

Айлык тәләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү елга бер айлык акчалата түләү күләменнән артмаган күләмдә билгеләнә.

Даими нигездә муниципаль вазыйфа башкаручы затның шәхси гаризасы нигезендә матди ярдәм түбәндәге очраклар белән бәйле рәвештә күрсәтелә:

- хезмәткәрнең баласы туу (һәр балага);
- хезмәткәрнең гаилә коруы;
- хезмәткрнең юбилей датасы (хатын-кызлар өчен – 50, 55 яшь, ир-атлар өчен – 50, 60 яшь);
- хезмәткәрнең ире (хатыны), балалары, әти-әнисе вафат булу;
- хезмәткәрнең авыр хәлләргә юлыгуы.

Матди ярдәм хезмәт өчен түләү фондын экономияләү хисабына тәүләнә, түләү өчен нигез булып эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле җитәкчесенең хокукый акты тора.

Акчалата түләү, акчалата бүләкләү, шулай ук айлык түләүләр һәм башка өстәмә тәләүләр күләме арттыру ягына таба тулы сумга кадәр түгәрәкләнә.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге Советының
2019 ел, «15» май, 78 нче
карарына
2 Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын алыштыручы затларга хезмәт өчен түләү турында Нигезләмә**

«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә ТР Арча муниципаль районы Яңа Кырлай  авыл җирлеге хезмәт өчен түләүнең унберенче төркеменә – халык саны 1 мең ярымнан 5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләргә керә.

Муниципаль хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү муниципаль хезмәткәрнең үзе биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә торган хезмәт окладыннан (алга таба – вазыйфаи оклад), шулай ук әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән айлык һәм башка өстәмә түләүләрдән тора.
Өстәмә түләүләргә түбәндәгеләр керә:
1) тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә тәләү;
2) муниципаль хезмәттә аеруча шартлар өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;
3) түләү тәртибе, муниципаль органның бурычларын һәм функцияләрен, вазыйфаи күрсәтмәләрне башкаруны исәпкә алып, эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннна билгеләнә торган аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне башкарган өчен премия;
4) айлык акчалата бүләкләү;
5) класслы чин өчен айлык өстәмә түләү;
6) еллык тәләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү;
7) матди ярдәм;

8) муниципаль хезмәткәрләргә нормалаштырылмаган эш көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләве.
Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, үзләре биләгән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль хезмәт муниципаль вазыйфасыннан чыгып, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме вазыйфаи окладı – 11 163 сум күләмендә билгеләнә.
Арча муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен билгеләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентлары:

| N | **Вазыйфа исеме** | **Коэффициент** |
|---|---|---|
| 1 | Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе | 1,50 |
| 2 | Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркатип) | 1,47 |
| 3 | Әйдәп баручы белгеч | 1,11 |
| 4 | 1 категорияле белгеч<br>2 категорияле белгеч<br>белгеч | 1,00 |

Тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә билгеләнә:

| Муниципаль хезмәт стажы | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан артык | 20 |

Муниципаль хезмәтнең махсус шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә ирешкән югары казанышлар, махсус эш режимы) өчен вазыйфаи окладка билгеләнә торган айлык өстәмә түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә билгеләнә:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары өчен – вазыйфаи окладның 9 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары өчен – вазыйфаи окладның 7 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары өчен – вазыйфаи окладның 5 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары өчен – вазыйфаи окладның 3 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары өчен – вазыйфаи окладның 1 процентыннан.

Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр башкарган өчен премия түбәндәге шартларны исәпкә алып түләнә:

1) премияләр вазыйфаи күрсәтмәләр һәм хезмәт килешүләре белән каралган вазыйфаларны вакытында һәм сыйфатлы итеп башкарган; җитәкчелекнең биремнәрен, әмерләрен һәм боерыкларын вакытында һәм сыйфатлы итеп үтәгән өчен премия түләү турында карар кабул ителгән көнгә җирле үзидарә органы белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган муниципаль хезмәткәрләргә түләнә;

2) премияләр барлык муниципаль хезмәткәрләргә берьюлы яки аерым бүлекчә муниципаль хезмәткәрләренә, шулай ук аерым муниципаль хезмәткәрләргә түләнергә мөмкин;

3) башка эшкә күчү, уку йортларына керү, әзерлек (квалификация), белем күтәрү курсларында уку, хезмәткәрләр яки штатны кыскарту буенча эштән китү, пенсиягә китү, йөклелек вакыты һәм бала табу буенча ялга китү, өч яшькә кадәр бала ялына китү һәм башка нигезле сәбәпләр белән бәйле рәвештә премия исәпләү өчен алынган вакыт аралыгында тулысынча эшләмәгән муниципаль хезмәткәрләргә премия әлеге исәп вакыт аралыгында фактта эшләнгән вакыт өчен түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә авыру буенча эштә булмаган вакыт өчен премия түләү һәр аерым очракта эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан карала;

4) премия исәпләү өчен алынган вакыт аралыгында җирле үзидарә органына эшкә кабул ителгән муниципаль хезмәткәрләргә премия аларның хезмәт өлешен исәпкә алып һәм фактта эшләнгән вакыт өчен түләнергә мөмкин;

5) календарь ел дәвамында муниципаль хезмәткәрләргә премия хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә исәпләнә;

6) премия исәпләү өчен вакыт аралыгы итеп айга, кварталга, яртыеллыкка, елга яки биремнәрне башкару өчен билгеләнгән башка вакытка тигез булган вакыт аралыгы алына;

7) премия суммалары максималь күләм белән чикләнмәгән;

8) аерым муниципаль хезмәткәрләргә, аларның гомуми эш нәтиҗәсенә керткән шәхси өлешен исәпкә алып, премия күләме арттырылырга мөмкин;

9) җитештерү ялгышы җибәргән һәм хезмәт дисциплинасын бозган муниципаль хезмәткәрләр тулысынча яки өлешчә премиядән мәхрүм ителә.

Тулысынча яки өлешчә премиядән мәхрүм итү җитештерү ялгышы һәм хезмәт дисциплинасын бозуга юл куелган премия түләү өчен алынган вакыт аралыгы өчен башкарыла.

Премия түләү эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча гамәлгә ашырыла һәм премия түләү өчен нигезләр һәм аның күләме күрсәтелгән хокукый акт белән рәсмиләштерелә.

Айлык акчалата бүләкләү вазыйфаи окладның 1 процентттан артмаган күләмендә билгеләнә.

Класслы чин өчен айлык өстәмә түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә билгеләнә:

| Класслы чин | Класслы чин өчен өстәмә түләү (вазыйфаи окладка карата процентларда) |
|---|---|
| I класслы гамәли муниципаль киңәшче<br>I класслы муниципаль киңәшче<br>I класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе<br>I класслы муниципаль хезмәт референты<br>I класслы муниципаль хезмәт сәркатибе | 7 |
| II класслы гамәли муниципаль киңәшче<br>II класслы муниципаль киңәшче<br>II класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе<br>II класслы муниципаль хезмәт референты<br>II класслы муниципаль хезмәт сәркатибе | 5 |
| III класслы гамәли муниципаль киңәшче<br>III класслы муниципаль киңәшче<br>III класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе<br>III класслы муниципаль хезмәт референты<br>III класслы муниципаль хезмәт сәркатибе | 3 |

Айлык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү 1,2 вазыйфаи окладтан артмаган күләмдә билгеләнә.

Муниципаль хезмәткәрнең шәхси гаризасы нигезендә матди ярдәм түбәндәге очраклар белән бәйле рәвештә күрсәтелә:

- хезмәткәрнең баласы туу (һәр балага);
- хезмәткәрнең гаилә коруы;
- хезмәткрнең юбилей датасы (хатын-кызлар өчен – 50, 55 яшь, ир-атлар өчен – 50, 60 яшь);
- хезмәткәрнең ире (хатыны), балалары, әти-әнисе вафат булу;
- хезмәткәрнең авыр хәлләргә юлыгуы.

Матди ярдәм хезмәт өчен түләү фондын экономияләү хисабына түләнә, түләү өчен нигез булып эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле җитәкчесенең хокукый акты тора.

Муниципаль хезмәткәрләргә нормалаштырылмаган эш шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләве вазыйфаи окладның 2 проценты күләмендә билгеләнә.

Эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фонды акчаларын әлеге Нигезләмә белән каралган түләүләр арасында яңадан бүләргә хокуклы.

Акчалата түләү, акчалата бүләкләү, шулай ук айлык түләүләр һәм башка өстәмә түләүләр күләме арттыру ягына таба тулы сумга кадәр түгәрәкләнә.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге Советының
2019 ел, «15» май, 78 нче
карарына
3 Кушымта

**Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында**
**Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге эшчеләренең хезмәт хакы айлык тариф челтәреннән, компенсация түләүләреннән, катлаулы һәм киеренке хезмәт өчен айлык тариф челтәренә айлык өстәмә түләүләрдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, еллык түләүле ял биргәндә бирелә торган матди ярдәмнән, класслык өчен айлык өстәмә түләүдән, профессияләрне берләштергән өчен, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйтү һәм төп эше белән беррәттән вакытлыча эштә булмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын алып барган өчен өстәмә түләүләрдән, шулай ук закон нигезендә башка түләүләрдән тора;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүдә эшләүче эшчеләргә хезмәт өчен түләү разрядлары диапазоны 5 Кушымта нигезендә билгеләнә;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге эшчеләренә тариф ставкалары һәм коменсация түләүләре 6,7 Кушымталар нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге эшчеләренә билгеләргә:

1) катлаулылык һәм киеренкелек өчен айлык тариф ставкасына, нормалаштырылмаган эш көне өчен хезмәт җиңел машиналары йөртүчеләренә түләнә торган өстәмәне исәпкә алмыйча, айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә айлык өстәмә түләү;

2) эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәрнең эш нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

3) еллык түләүле ял бирелгәндә, айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендәге премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы күләмендә матди ярдәм.

Әгәр календарь ел дәвамында эшчегә еллык түләүле ял бирелмәгән булса, еллык түләүле ял бирелгәндә түләнә торган матди ярдәм аңа декабрь аенда эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм түләнә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча.

Беренче эш елында еллык түләүле ялга киткәндә бирелә торган матди ярдәм календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә кадәр

санала.

4) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә матди ярдәм;

5) хезмәт җиңел машиналары йөртүчеләргә класслык өчен айлык өстәмә түләү түбәндәге күләмдә:

I классны йөртүчеләргә – йөртүче сыйфатында эшләгән вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә;

II классны йөртүчеләргә – йөртүче сыйфатында эшләгән вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасының 10 проценты күләмендә;

6) айлык өстәмә түләү:

профессияләрне берләштергән өчен, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйтү һәм төп эше белән беррәттән вакытлыча эштә булмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын алып барган өчен – гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә төп эш урыны буенча айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә;

төнлә (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) эшләгән өчен – сәгатьлек тариф ставкасының 35 проценты күләмендә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен – икеләтә көнлек тариф ставкасы күләмендә;

хезмәт җинел машинасын йөртүчеләргә нормалаштырылмаган эш көне өчен – айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә.

3. Хезмәткәрләргә федераль законнар, Татарстан Республикасы Законнары һәм башка норматив хокукый актлар белән каралган башка тәүләүләр түләргә.

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге эшчеләренә хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда тариф ставкалары түләүләре (компенсация түләүләрен исәпкә алып) суммаларыннан тыш түләү өчен түбәндәге акчалар күздә тотыла (еллык исәп белән):

1) катлаулы һәм киеренке эш өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә түләү – бер айлык тариф ставкасы күләмендә;

2) машина йөртүчеләргә класслык, нормалаштырылмаган эш көне өчен айлык өстәмә түләү – тугыз айлык тариф ставкасы күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премия – өч айлык тариф ставкасы күләмендә;

4) еллык түләүле ял биргәндә бирелә торган матди ярдәм – айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы күләмендә.

5. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләр күләме арттыру ягына таба тулы сумга кадәр түгәрәкләнә, дип билгеләргә.

Яңа Кырлай авыл
жирлеге Советының
2019 ел, «15» май, 78 нче
карарына
4 Кушымта

**<u>Татарстан</u> Республикасы Арча муниципаль районы**
**Яңа Кырлай авыл җирлегендә баш хисапчыга хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында**
**Нигезләмә**

Әлеге Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегендә баш хисапчыга хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) (алга таба – баш хисапчы) баш хисапчы эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлаштыра һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын, компенсация һәм стимуллаштыручы түләүләр күләмен һәм аларны түләү шартларын билгели.

2. Баш хисапчының эш хакы вазыйфаи окладтан, тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

3. Баш хисапчының вазыйфаи оклады түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары халык саны белән |
|---|---|
| | 3 мең ярым кешегә кадәр |
| Баш хисапчы | 15 700 сум |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге штат расписаниесына баш хисапчы вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлектәге халык санының 3 мең ярым кешедән артуы тора.

4. Баш хисапчыга билгеләнә:

1) тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү түбәндәге күләмдә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә түләү, процентларда |
|---|---|
| 1 дән 5 елга кадәр | 5 |
| 5 тән 10 елга кадәр | 7 |

| | |
|---|---|
| 10 нан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү – вазыйфаи окладка 10 процент күләмендә;

3) еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү – елга вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә.

Әгәр календарь ел дәвамында баш хисапчыга еллык түләүле ял бирелмәгән булса, бер тапкыр бирелә торган түләү аңа декабрь аенда эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм түләнә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча.

Беренче эш елында еллык түләүле ялга киткәндә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә кадәр санала.

4) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм.

Эш нәтиҗәләре буенча премия түбәндәге шартларны исәпкә алып түләнә:

1) премияләр вазыйфаи күрсәтмәләр һәм хезмәт килешүләре белән каралган вазыйфаларны вакытында һәм сыйфатлы итеп башкарган; җитәкчелекнең биремнәрен, әмерләрен һәм боерыкларын вакытында һәм сыйфатлы итеп үтәгән өчен премия түләү турында карар кабул ителгән көнгә җирле үзидарә органы белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган баш хисапчыга түләнә;

2) башка эшкә күчү, уку йортларына керү, әзерлек (квалификация), белем күтәрү курсларында уку, хезмәткәрләр яки штатны кыскарту буенча эштән китү, пенсиягә китү, йөклелек вакыты һәм бала табу буенча ялга китү, өч яшькә кадәр бала ялына китү һәм башка нигезле сәбәпләр белән бәйле рәвештә премия исәпләү өчен алынган вакыт аралыгында тулысынча эшләмәгән баш хисапчыга премия әлеге исәп вакыт аралыгында фактта эшләнгән вакыт өчен түләнә. Баш хисапчыга авыру буенча эштә булмаган вакыт өчен премия түләү һәр аерым очракта эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан карала;

3) премия исәпләү өчен алынган вакыт аралыгында җирле үзидарә органына эшкә кабул ителгән баш хисапчыга премия аның хезмәт өлешен исәпкә алып һәм фактта эшләнгән вакыт өчен түләнергә мөмкин;

4) календарь ел дәвамында баш хисапчыга премия хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә исәпләнә;

5) премия исәпләү өчен вакыт аралыгы итеп айга, кварталга,

яртыеллыкка, елга яки биремнәрне башкару өчен билгеләнгән башка вакытка тигез булган вакыт аралыгы алына;

6) премия суммалары максималь күләм белән чикләнмәгән;

7) баш хисапчыга, аның гомуми эш нәтиҗәсенә керткән шәхси өлешен исәпкә алып, премия күләме арттырылырга мөмкин;

8) җитештерү ялгышы җибәргән һәм хезмәт дисциплинасын бозган баш хисапчы тулысынча яки өлешчә премиядән мәхрүм ителә.

Тулысынча яки өлешчә премиядән мәхрүм итү җитештерү ялгышы һәм хезмәт дисциплинасын бозуга юл куелган премия түләү өчен алынган вакыт аралыгы өчен башкарыла.

Премия түләү эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары белән башкарыла һәм премия түләү өчен нигезләр һәм премия күләме күрсәтелгән хокукый акт белән рәсмиләштерелә.

6. Баш хисапчының шәхси гаризасы нигезендә матди ярдәм түбәндәге очраклар белән бәйле рәвештә күрсәтелә:

- бала туу (һәр балага);
- гаилә кору;
- юбилей датасы (хатын-кызлар өчен – 50, 55 яшь, ир-атлар өчен – 50, 60 яшь);
- ире (хатыны), балалары, әти-әнисе вафат булу;
- авыр тормыш хәлләренә юлыгу.

Матди ярдәм хезмәт өчен түләү фондын экономияләү хисабына түләнә, түләү өчен нигез булып эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле җитәкчесенең хокукый акты тора.

7. Баш хисапчыга хезмәт хакы түләүнең еллык фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \mathrm{P} * (1 + t);$$

анда:

$FOT$ – баш хисапчының хезмәт хакының еллык фонды;

$O_d$ – баш хисапчыга вазыйфаи оклад түләү суммасы;

$0{,}3 * O_d$ – тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, айлык бүләкләү, еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү, матди ярдәм суммасы;

Р – хисапчыларның еллык премия фонды (*әлеге Нигезләмәнең 3 пункты 5 подпункты белән билгеләнгән шартлар белән билгеләнә*);

$n$ – штаттагы хисапчылар саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт өчен түләү исәпләүләр.

8. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге баш хисапчысына айлык акчалата һәм башка түләүләр күләме арттыру ягына таба тулы сумга кадәр түгәрәкләнә, дип билгеләргә.

9. Әлеге карарны кабул итү белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең башка шартлары кулланылмый.

Татарстан Республкасы
Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл
җирлеге Советының
2019 ел, «15» май, 78 нче
карарына
5 Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүдә эшләүче эшчеләргә хезмәт өчен түләү разрядлары диапазоны**

| Профессия исеме | Хезмәт өчен түләү разряды |
|---|---|
| Чишенү бүлмәсе эшчесе, ишегалды себерүче, курьер | 1 |
| Каравылчы (вахтер), җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручы, лифтер, кладовщик, йөк төяүче | 1 – 2 |
| Электрон-исәпләү һәм исәпләү машиналары операторы, биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү буенча эшче | 2 – 4 |
| Күчермә ясау һәм күбәйткеч машина операторы | 2 – 3 |
| Җиңел машина йөртүче | 4 – 5 |

Искәрмә:

Җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручыларга икенче разрядлы тариф ставкасы җитештерү биналарын, шул исәптән җитештерү калдыкларын, санитар челтәрләрне, җәмәгать бәдрәфләрен җыештырган өчен билгеләнә.

Машина йөртүчеләргә бишенче разрядлы тариф ставкасы ике–өч җиңел машинада эшләгән өчен, шулай ук машиналарны техник төзекләндерү махсус хезмәте булмаган очракта машинаны төзекләндерү һәм техник хезмәт күрсәтү буенча барлык эшләрне башкарган өчен билгеләнә.

Татарстан Республкасы Арча
муниципаль районы Яңа
Кырлай авыл җирлеге
Советының
2019 ел, «15» май, 78 нче
карарына
6 Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге бюджет олкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)**

| Бердәм тариф челтәре түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлары), сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 2329 |
| 2 | 1,047 | 2438 |
| 3 | 1,09 | 2539 |
| 4 | 1,142 | 2660 |
| 5 | 1,268 | 2953 |
| 6 | 1,407 | 3277 |
| 7 | 1,546 | 3601 |
| 8 | 1,699 | 3957 |
| 9 | 1,866 | 4346 |
| 10 | 2,048 | 4770 |
| 11 | 2,241 | 5219 |
| 12 | 2,423 | 5643 |
| 13 | 2,617 | 6095 |
| 14 | 2,813 | 6551 |
| 15 | 3,035 | 7069 |
| 16 | 3,260 | 7593 |
| 17 | 3,511 | 8177 |
| 18 | 4,499 | 10478 |

Татарстан Республкасы
Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл
җирлеге Советының
2019 ел, «15» май, 78 нче
карарына
7 Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге бюджетыннан финанслана торган бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә компенсация түләүләре күләме**

| Бердәм тариф челтәре хезмәт өчен түләү разрядлары | Компенсация түләүләре, сумнарда |
|---|---|
| 1 | 3383,00 |
| 2 | 3283,00 |
| 3 | 3193,00 |
| 4 | 3082,00 |
| 5 | 2805,00 |
| 6 | 2780,00 |
| 7 | 2704,00 |
| 8 | 2692,00 |
| 9 | 2692,00 |
| 10 | 2680,00 |
| 11 | 2673,00 |
| 12 | 2673,00 |
| 13 | 2673,00 |
| 14 | 2673,00 |
| 15 | 2673,00 |
| 16 | 2673,00 |
| 17 | 2673,00 |
| 18 | 2673,00 |